СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/3

На №__________ от______________

# КАРАР

## Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы 4 пункты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставының 6 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының әйләнә-тирә мохитне саклау вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының әйләнә-тирә мохитне саклау вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының әйләнә-тирә мохитне саклау вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак, Күзкәй, Князево авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1-3 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар планы чорына Татарстан Республикасы

Тукай муниципаль районы бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм карауга тапшырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров